Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл жирлеге советы
423066 **ЯңаКармәт** авылы
Муса Җәлил урамы,15а нче йорт
тел. 4-92-33 факс
Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт
Яңа Кармәт авылы , 4203066

Совет Новокиреметского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
42306 с.Новая Киреметь
улица Мусы Джалиля, д.15а
тел. 4-92-33 факс
ул. Мусы Джалиля, д 15а,
с.Новая Киреметь, 423066

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail: *Nkir.Aks@tatar.ru*

КАРАР

2023 елның 22 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Рус Кармәте авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып, түбәндәге сораулар буенча 2023 елның 15 ноябрендә һәм 22 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Рус Кармәт авылында узган гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1."2024 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Рус Кармәте авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, урамнарны кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтү.

- Рус Кармәте авылы урамнары буйлап вак таш белән капланган (сатып алу, ташу, җәю, вак таш, туфракны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) юллар төзелеше;

“ӘЙЕ” “ ЮК” “ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 187 гражданин кертелгән, тавыш бирүдә 104 гражданин катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 96 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 8 кеше тавыш бирде.
- "тыелып калды" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Рус Кармәте авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

1."2024 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Рус Кармәте авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, урамнарны кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтү.

- Рус Кармәте авылы урамнары буйлап вак таш белән капланган (сатып алу, ташу, җәю, вак таш, туфракны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) юллар төзелеше;

3. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә,http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәмhttp://pravo.tatarstan.ru/Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров